РЕШЕНИЕ КАРАР

28 .11. 2016 № 15-9

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәплэнгән нигездә файдалануга бирү өчен, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән җир кишәрлекләреннән тыш, Тәтеш муниципаль районы муниципаль милкен арендага бирү тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү шартларында муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, аларга милек ярдәме күрсәтү максатларында, Тәтеш муниципаль районы Советы карар кылды:

1. »Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка исәплэнгән нигездә файдалануга бирү өчен, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән (1 нче кушымта) Тәтеш муниципаль районы муниципаль милкен арендага бирү тәртибен расларга

2. Тәтеш муниципаль районы Советының 28.09.2009 ел, №33-3 карары белән расланган Тәтеш муниципаль районы муниципаль торак булмаган фондны арендалау шартнамәләрен төзү тәртибе турындагы Нигезләмәнең гамәлдә булуы, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү өчен, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән Тәтеш муниципаль районы муниципаль милкенә кагылмый.;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башлыгы урынбасары Е.г. Курковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Тәтеш муниципаль районы

Башлыгы Р.Х. Сафиуллов